**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы**

Актюбинский ш.т.б. № 67 «13» декабрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының «Җир салымы турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 41 номерлы карарына үзгәреш кертү турында (2017 елның 5 сентябрендәге 17 номерлы, 2018 елның 15 октябрендәге 53 номерлы карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының II өлешенең 31 бүлеге 387 статьясы нигезендә

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыц Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының «Җир салымы турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 41 номерлы карарына (2017 елның 18 августындагы 21 номерлы, 2017 елныц 5 сентябрендәге 17 номерлы, 2018 елның 15 октябрендәге 53 номерлы карарлар редакциясендә) 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5.1 пунктчасын өстәргә:

«5.1. Салым ташламаларының муниципаль берәмлекләрнең башкарма хакимият органнарына милекче булган яки даими (срогы чикләнмәгән) файдалануга рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләре өлешендә «җитештерү һәм административ биналар, төзелешләр, сәнәгать, коммуналь хуҗалык корылмаларын, матди-техник, азык-төлек белән тәэмин итү, сату һәм әзерләү өчен " рөхсәт ителгән куллану өлешендә тапшырыла дип билгеләргә.».

2. Әлеге карар рәсми басма - «Маяк» газетасында басылып чыккан көннән бер ай узгач үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны район «Маяк» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aznakayevo.tatastan.ru. урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советыныц Бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.А. Галеева